**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында : «I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Карашай-Саклау авылында урнашкан коеларны төзү ,ремонтлау:Гагарин урамындагы коены ремонтлау, материаллар сатып алу;

2) Торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү:

- Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, йөртүче хезмәтләре өчен түләү)

Карашай-Саклау торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу(эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ) ;

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту :

- вак таш түшәмәне ремонтлау(махсус техниканы арендалау, эшләрне һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләрне түләү, вак ташу һәм салу, Су Буе урамында грейдерлау)

4) Көнкүреш калдыклары, чүп-чар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус аренда.Карашай-Саклау т. п.;

5) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү :

- янгын сүндерү емкосы өчен авторезина һәм мотопомпа сатып алу

4. Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыклары, чүп-чарлар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус техника яллау )

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева